БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» 09 2024 ел № 226

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы буенча
2024 елның IV кварталына гомуми торак мәйданының
бер квадрат метрының бәясен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 30 декабрендәге «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү турында» 1710 номерлы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү турында» 1050 номерлы карарлары белән расланган Россия Федерациясе дәүләт программаларының аерым чараларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 октябрендәге «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү турында» дәүләт программасын раслау хакында» 888 номерлы карарына яраклы рәвештә, «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» бәйсез партнерлык эксперт-консультация советының 2024 елның 22 июлендәге «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 214 номерлы хаты һәм Балтач муниципаль районы торак комиссиясенең 2024 елның 11 сентябрендәге 12 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «2020 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру кысаларында Балтач муниципаль районы территориясендә 2024 елның IV кварталына гомуми торак мәйданының бер квадрат метрының бәясен 47 345 сум 00 тиен күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi. tatarstan.ru) халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов